**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 6 июнендәге 2349 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 16 ноябрендәге 3555 номерлы карары белән расланган Оренбург Тракты урамындагы территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карарлары нигезендә, 2023 елның 28 ноябрендәге техник биремне исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 16 ноябрендәге 3555 номерлы карары белән расланган Оренбург Тракты урамындагы территорияне планлаштыру проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарның кушымтасы нигезендә раслау юлы белән, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 6 июнендәге
2349 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 16 ноябрендәге 3555 номерлы карары белән расланган Оренбург Тракты урамындагы территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. IV бүлекнең 3 пунктында:

1.1. таблицада 15, 16, 19 юлларны төшереп калдырырга (16:50:070505:3, 16:50:070505:4, 16:50:070508:3 кадастр номерлы җир кишәрлекләре);

1.2. түбәндәге эчтәлекле таблицага искәрмә өстәргә:

«Кадастр эшләре башкару яки җир кишәрлегенең кадастр номеры үзгәрүгә китергән башка гамәлләр кылу нәтиҗәсендә мәҗбүри алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләренең кадастр номерлары үзгәрү мәҗбүри алу турында карар кабул итү өчен каршылык булып тормый һәм әлеге территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертүне таләп итми»;

1.3. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Рөхсәт ителгән файдалану төре – шәхси торак төзелеше өчен булган һәм шундый ук (16:50:070504:4, 16:50:070504:11, 16:50:070504:12, 16:50:070504:46, 16:50:070504:47, 16:50:070504:362 кадастр номерлы җир кишәрлекләре), өлешчә әлеге территорияне планлаштыру проекты чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары, атап әйткәндә, җир кишәрлегенең минималь зурлыгы Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында»гы карары (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 24 статьясының 6 пункты нигезендә, 400 кв.м күләмендә билгеләнә».

___________